**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29.11.2023 ел** **№ 1817**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда өченче һәм аннан күбрәк сыерлар сатып алуга һәм карап тотуга чыгымнар өлешен компенсацияләүгә субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 02 июнендәге 557 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасы протестына бәйле рәвештә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерм нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда өченче һәм аннан күбрәк сыерлар сатып алуга һәм карап тотуга чыгымнар өлешен компенсацияләүгә субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 02 июнендәге 557 номерлы карарына (05.09.2022 №879, 08.02.2023 №216 карарлары белән кертелгәннәрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 9, 9.1, 9.2 пунктларны өстәргә:

«9. Әлеге Тәртипнең 5 бүлегенең 1 пунктында күрсәтелгән документлар кергәндә һәм 2 пунктының таләпләренә туры килгәндә, Башкарма комитет:

- номерланган, шнурланган һәм мөһер белән беркетелгән журналга кергән көнендә аңа кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны теркәп куя. Гаризаны теркәгәндәге номер керү датасын һәм вакытын үз эченә алырга тиеш;
- гаризаны теркәгәннән соң 30 эш көне эчендә башкаручы тапшырылган документларны муниципаль берәмлек бюджетыннан субсидияләр бирү Комиссиясе каравына җибәрә.

9.1. Гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия бирелгән документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга

туры килүгә тикшерә һәм документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе яисә аларның туры килмәве турында карар кабул итә.

9.2. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- әлеге Тәртипнең 5 бүлегенең 1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә 2 пункт буенча күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет бу хакта субсидия алучыга 5 бүлекнең 7 пункты нигезендә хәбәр итә.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин